ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**КАРАР**

2020 елның «30» апреленнән № 102

**«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль учреждениеләре җитәкчеләре тарафыннан 2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәрге хисап чорында керемнәр, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү тәртибе турында»**

Россия Федерациясе Президентының «2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр хисап чорында керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүмат тапшыру хакында" 2020 елның 17 апрелендәге 272 номерлы Указы, Татарстан Республикасы Президентының «2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр хисап чорында керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында мәгълүматлар тапшыру хакында» 2020 елның 24 апрелендәге ПУ-250 номерлы Указы, "Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы башкарма комитеты **карар бирә**:

1. Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль учреждениеләре җитәкчеләре, шулай ук Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль учреждениеләре җитәкчеләре вазыйфасына керешүче затларның керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 28 мартындагы 167 номерлы карары белән расланган мәгълүматлар тапшыру турындагы Нигезләмәдә

каралган 2019 елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр хисап чорында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль учреждениеләре җитәкчеләре тарафыннан үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру срогын 2020 елның 1 августына кадәр озайтырга.

2. Әлеге карарны “Интернет” мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы"нда (http:/ / pravo. tatarstan. ru) һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru. бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының кадрлар секторы мөдиренә йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Башкарма комитеты**
**Җитәкчесе** **Р.Р. Фәсахов**